**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛЛӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXXIV УТЫРЫШЫ**

КАРАР № 62

Мәллә-Тамак авылы “ 25 ” октябрь 2023 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советының 2014 елның “18” декабрь 68 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 1 июлендәге 286-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлегенд муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкә һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында», Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советының 2014 елның “18”декабрь 68 номерлы карарына 16 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

1.1. “ Муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яисә үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яисә мондый белешмәләр бирү мәҗбүри булган очракта, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү хокук бозу булып тора, аларны алмаштырыла торган вазифаларыннан азат итүгә, муниципаль хезмәттән билгеләнгән тәртипта эштән азат итүгә китерә.”.

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мәллә-Тамак авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Насифуллина